| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**13.01.2016** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 42_** |

2016 елга Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, 2003 елның 06 октябрендәге 131 номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, 2007 елның 21 декабрендәге 1879 номерлы «Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларына норматив финанслауны кертү турында” карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

## КАРАР БИРӘ:

1.2016 елга кушымта итеп расларга:
Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнар;

2."Зеленодольск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы" муниципаль учреждениесенә белем бирү оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә белем бирү оешмаларын финанслауны тәэмин итү:

2015 елның 17 октябрендәге 87 номерлы «2016 елга Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» Татарстан Республикасы Законы белән расланган;

әлеге карарның 1 пункты белән.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2016 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4 Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - мәгариф идарәсе башлыгы Р.В. Афанасьевага йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А. В. Старостин

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты 2016 елның 13 гыйнварендәге 42 номерлы карары белән расланган

**Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрдә тәрбияләнүчеләрне карауга**
**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Гомуми белем бирү оешмасының тибы һәм төре | Территориаль урнашу | Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, елга сум |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасында интернат | шәһәр җирлеге | 60013 |
| | авыл җирлеге | 61372 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | шәһәр җирлеге | 91227 |
| | авыл җирлеге | 94896 |